**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

31.05.2018 № 384

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 ел,
19 февраль, 118 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан республикасы әтиләр Советы эшчәнлеген активлаштыру һәм кадрлар үзгәреше уңаеннан

КАРАР БИРӘМ:

1. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 ел, 19 февраль, 118 нче “Нурлат муниципаль районында “Әтиләр Советы” иҗтимагый оешмасын булдыру турында” карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.“Әтиләр Советы” иҗтимагый оешмасының Нурлат бүлеге әгъзалары исемлеген яңа редакциядә расларга (1 нче Кушымта);

1.2. Әтиләр Советының 2018 елга эш планын расларга (2 нче Кушымта);

1.3. Республика “Әтиләр Советы” иҗтимагый оешмасының Нурлат бүлеге турында нигезләмәсен расларга (3 нче Кушымта).

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.С. Әхмәтшин

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының

2018 ел, 31 май, 384 номерлы
карарына 1 нче Кушымта

“Әтиләр Советы” иҗтимагый оешмасының Нурлат бүлеге әгъзалары исемлеге

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Әхмәтҗанов И.Р. | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары; рәис; |
| 2. | Хәмзин Р.Р. | Нурлат шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча); |
| 3. | Маняпов Л.Н. | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең мәгариф буенча урынбасары; |
| 4. | Нәбиуллин Ә.Ә. | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге мөдире; |
| 5. | Кәримов И.Г. | “Нурлат автотранспорт предприятиесе” генераль директоры, Нурлат районы кеше хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкиле (килешү буенча) ; |
| 6. | Сәгъдиев А.Р. | “Нурлат үзәк хастаханәсе” баш табибы (килешү буенча); |
| 7. | Әбелханов Н.Б. | Нурлат муниципаль районы мөхтәсибе |
| 8. | Борков А.А. | благочинный, Казан епархиясе православие дини оешмасы Нурлат шәһәре Илья чиркәве Приходы рухание |
| 9. | Ягудин Ш.Г. | “Зюзеевнефть-Татнефтепром» ААҖ генераль директоры (килешү буенча). |

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты
2018 ел, 31 май, 384 номерлы
карарына 2 нче Кушымта

# “Әтиләр Советы” иҗтимагый оешмасы Нурлат бүлегенең 2018 елга эш планы

| № т/с | Чаралар | Уткәрү вакыты | Җаваплылар (килешү буенча) |
|---|---|---|---|
| 1. | Әтиләр Советы әгъзаларының очрашуларын оештыру | ел дәвамында | Әхмәтҗанов И.Р.-Район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары |
| 2. | Имин булмаган гаиләләрдәге балалар белән профилактик чаралар | ел дәвамында | Гәләветдинова Ә.С.-Район башкарма комитеты җитәкчесенең иҗтимагый-мәдәни мәсьәләләр буенча урынбасары |
| 3. | Балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны кисәтү Советы утырышларында катнашу | График нигезендә айга 1 тапкыр | Хәмзин Р.Р.-Нурлат шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе |
| 4. | Массакүләм спорт чараларында катнашу | ел дәвамында | Нәбиуллин Ә.Ә.- район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт булеге мөдире |
| 5. | Каникул вакытларында һәм бәйрәм коннәрендә җәмәгать урыннарында кисәтү рейдлары | ел дәвамында | Маняпов Л.Н.-район Башкарма комитеты җитәкчесенең мәгариф буенча урынбасары |
| 6. | Район күләмендә үздырылучы хәрби хезмәткә чакырылучылар өчен уздырылучы чараларда катнашу | язгы һәм көзге чакырылышларда | Нәбиуллин Ә.Ә.- район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт булеге мөдире |
| 7. | Укучылар белән тормыш куркынычсызлыгы һәм сәламәт яшәү нигезләренә кагылышлы әңгәмәләр уздыру | сентябрь | Нәбиуллин Ә.Ә.- район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт булеге мөдире |
| 8. | Гаилә тәрбиясенең уңай тәҗрибәсе белән уртаклашу. “Гаилә бәхете” фотокүргәзмәсе | сентябрь | Әбелханов Н.Б – район мөхтәсибе Борков В.А.- рухани, Илья чирәве настоятеле |
| 9. | “Тәрбия мәсьәләләре. Буыннар каршылыгы” темасына түгәрәк өстәл | ноябрь | Нәбиуллин Ә.Ә.- район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт булеге мөдире |
| 10. | Массакүләм мәгълүмат чараларында Совет эшчәнлеген яктырту | ел дәвамында | Гиняева Р.Ә.-“Татмедиа” АҖ Нурлат филиалы директоры |
| 11. | Советның йомгаклау утырышы | декабрь | Әхмәтҗанов И.Р.-район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары |

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

2018 ел, 31 май, 384 номерлы
карарына 3 нче Кушымта

“Татарстан Республикасы
Әтиләр Советы” иҗтимагый оешмасының
Нурлат бүлеге НИГЕЗЛӘМӘСЕ

“Татарстан Республикасы Әтиләр Советы” иҗтимагый оешмасының Нурлат бүлеге (алга таба – Бүлек) аерым бүлекчә буларак, Республика “Әтиләр Советы” ( алга таба – Совет) иҗтимагый оешмасы функциясен өлешчә гамәлгә ашыручы вәкил булып тора.

Әлеге бүлекнең вәкаләтләре Нурлат муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла һәм Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясенең иҗтимагый берләшмәләре турындагы Федераль Законга таянып, шулай ук Советның Уставы нигезендә алып барыла. Әлеге Бүлек дәүләт учреждениеләре һәм иҗтимагый оешмалар, массакүләм мәгълүмат чаралары, Россия Федерациясе гражданнары белән Советның эшчәнлеген гамәлгә ашыруга кагылышлы сораулар буенча тыгыз элемтәдә тора. Әлеге Бүлек юридик зат булып саналмый. Бүлек Советның милекчесе булып торырга мөмкин. Бүлек эшчәнлегенең төп юнәлешләре Совет Уставы нигезендә билгеләнә.

Бүлек:

Советның мәнфәгатьләрен чагылдыра, Нурлат муниципаль районы территориясендә аларны яклауны гамәлгә ашыра;

Советның максатларын ирештерүдә, бигрәк тә гаилә һәм мәгариф учреждениеләренең, җәмгытьнең бәйләнешен ныгытуда әһәмиятле роль уйный;

әтиләрнең белем бирү учреждениеләре үсешен тәэмин итү өчен шартлар тудыруда катнашуына теләктәшлек итә;

гаилә тәрбиясенең уңай тәҗрибәсе белән уртаклашуны пропагандалый;

ата-аналарның балалар тәрбияләү өлкәсендә җаваплылыгы артуын күрсәтә, аларга балаларының җәмгыятьтә үз урынарын табуда, тормыш авырлыкларын җиңәргә өйрәнүдә теләктәшлек белдерә, социаль ярдәм тәэмин итә, яшүсмерләр белән чаралар уздыра; балигъ булмаган балаларның караучысызлыгына каршы көрәш һәм аларның хокук бозуларын кисәтү өстендә эш алып бара;

район һәм шәһәр җәмәгатьчелегендә ата-аналар берлекләре роле, аның район һәм шәһәр иҗтимагый - сәяси тормышында тоткан урынын билгели;

Нурлат муниципаль районы территориясендә яшәүче Совет әгъзаларына Бүлекнең эш тәртибе, үткәрелүче чаралар хакында һәрдаим мәгълүмат биреп тора;

Бүлек составына Устав нигезендә яңа әгъзалар кабул итүне һәм чыгаруны башкара;

Нурлат муниципаль районында Бүлек әгъзаларының эшләр тәртибен алып бара;

Бүлек эшчәнлегенә кагылышлы еллык һәм квартал отчётларын хәзерли;

Бүлекнең рәисе вазыйфаларын сайлау нәтиҗәсендә куелган җитәкче башкара.

Бүлекнең рәисе:

барлык идарә итү эшләрен оештыра, башка оешмалар һәм учреждениеләрдә бүлек мәнфәгатьләрен яклый;

Бүлекнең көндәлек эшчәнлеге буенча карарлар кабул итә;

киңәшмәләр һәм бүлек утырышларын хәзерли һәм уздыра;

район әтиләр Советы рәисе бүлек әгъзалары эшчәнлеген даими контрольдә тота.

Бүлекнең урнашу урыны гомуми утырышта билгеләнә һәм раслана;

бүлекнең вәкаләтләре, кирәк түгел дип табылган очракта, закон тарафыннан якланылган очраклардан гайре, гомуми утырыш карары нигезендә юкка чыгарыла;

әлеге Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү Бүлек әгъзаларының гомуми утырышы карары нигезендә башкарыла.